ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

29 май 2020ел

**КАРАР**

№ 2568

Башкарма комитетның 2014 елның 8 декабрендәге 7608 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына керешүче зат тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 275 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/18 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Башкарма комитетның 2014 елның 8 декабрендәге 7608 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына керешүче зат тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемдә «зат» сүзен «граждан» сүзенә алмаштырырга;

2) 1 пунктта «зат» сүзен «граждан» сүзенә алмаштырырга;

3) 4 пунктта «ел саен хисап елыннан соң килгән елның 30 апреленнән соңга калмый» сүзләрен «ел саен, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү өчен билгеләнгән срокларда» сүзләренә алмаштырырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов